СОВЕТ СТАРОМАТВЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ МАТВЕЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

17.10.2022 ел

№ 8

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлеге составына керүче Иске Матвеевка торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законнын 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 17.10.2022 елдагы гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:"Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлеге Иске Матвеевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме, түбәндәгеләрдән тыш: *көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, мобилизацияләнгәнһәм аларның гаилә әгъзалары*һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлтү:

1. Иске Матвеевка торак пунктында зират территориясендә койма алыштыру (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;
2. Иске Матвеевка торак пунктында һәйкәл территориясендә койма алмаштыру (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;
3. Авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, күчерү, салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) Иске Матвеевка торак пункты Петровка ур., Болынлы ур.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия жыенда катнашучылар исемлегенә 214 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 150 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында 150 катнашучы «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен жыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлегенең Иске Матвеевка торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.
Сорау буенча карар кабул ителде дип танырга:"Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлеге Иске Матвеевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә ризамы,көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзалары һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

1. Иске Матвеевка торак пунктында зират территориясендә койма алыштыру (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;
2. Иске Матвеевка торак пунктында һәйкәл территориясендә койма алмаштыру (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;
3. Авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, күчерү, салу, килешү буенча эшләр өчен түләү) Иске Матвеевка бистәсендә, Петровка ур., Луговая ур.

2. Иске Матвеевка авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Минзәлә муниципаль районы сайтында гражданнар җыенының нәтиҗәләрен халыкка игълан итү http://menzelinsk.tatarstan.ruТатарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo tatarstan урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә.
3. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: ____________ Д.Г. Шакиров
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Иске Матвеевка авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе ____________ Д.Г. Шакиров
(имза) (имзаның аңлатмасы)